# КАРАР

**2022 елның 05 декабре** **№ 30**

**Кукмара муниципаль районы Пычак авыл җирлегенең Әсән-Елга авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча үткәрелгән гражданнар җыены нәтиҗәсе турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2022 елның 02 декабрендә 13.00 сәгатьтә һәм 2022 елның 02 декабрендә 19.00 сәгатьтә түбәндәге мәсьәлә буенча узган гражданнар җыеннары нәтиҗәләре буенча гражданнар җыены беркетмәсе төзелде:

«Сез 2023 елда Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Пычак авыл җирлегенең Әсән-Елга авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, I төркем инвалидларыннан, көндезге уку формасы буенча белем алучы укучылар һәм студентлардан (курсантлар), 85 яшьтәге һәм аннан өлкәнрәк затлардан кала, үзара салымны 700 сум күләмендә кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен юнәлтүгә сез ризамы:

-Әсән-Елга авылына тышкы видеокүзәтү камералары сатып алу һәм урнаштыру (килешү буенча хезмәтләр һәм эшләр өчен түләү);

- Әсән-Елга авылының су башнялары өчен насослар сатып алу һәм урнаштыру (килешү буенча эш өчен түләү);

- Әхмәт Юныс урамындагы сүүткәргеч челтәрен ремонтлау һәм су башнясын алыштыру (проект-смета документларын эшләү, килешү буенча түләү);

- су башнясы коймасын ремонтлау, төзелеш материаллары һәм коелар сатып алу;

- энергия саклагыч урам утлары, яктырткычлар, махсус җиһазлар сатып алу һәм урнаштыру (килешү буенча эш өчен түләү);

- кар чистарту техникасы сатып алу;

- янгын сүндерү җиһазлары сатып алу;

- банерлар әзерләү һәм сатып алу (проект-смета документларын эшләү, килешү буенча эшләр өчен түләү);

- Әсән-Елга авылында Яр буе урамына вак таш җәю, вак таш сатып алу, ташу, җәю (проект-смета документларын эшләү һәм әзерләү, техник күзәтчелекне тормышка ашыру, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);

- Пычак авылы Мәхмүт Яхин урамында машина-трактор паркыннан «Пычак урта гомуми белем бирү мәктәбе» МБГББУга кадәр юлга асфальт җәю (проект-смета документларын эшләү һәм әзерләү, техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, экспертиза)

- Әсән-Елга авылының урам юл челтәрен карап тоту (юлларны кардан чистарту һәм җәй көне территорияне чабу; ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);

- Әсән-Елга авылы территориясен төзекләндерү, торак пункт билгесе урнаштыру (проект-смета документларын эшләү һәм әзерләү ,килешү буенча эшләр өчен түләү), төзелеш материаллары сатып алу;

- чишмәне ремонтлау һәм карап тоту (проект-смета документларын әзерләү һәм килешү буенча түләү);

- зиратны төзекләндерү һәм карап тоту; зиратка капка ясау (төзелеш материаллары сатып алу);

- коры агачларны һәм куакларны кисү, кисеп ату, төпләү, санитар эшкәртү;

- мәдәният йорты өчен спорт җиһазлары һәм музыка кораллары сатып алу.

«РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыены карары нигезендә: Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә **285** кеше кертелде, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны **148**.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен җыенда катнашкан 148 кеше тавыш бирде;

«Юк» позициясе өчен җыенда катнашкан **0** кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Пычак авыл җирлеге Әсән-Елга авылында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыенының нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.
2. Түбәндәге мәсьәлә буенча карарны: «Сез 2023 елда Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Пычак авыл җирлегенең Әсән-Елга авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, I төркем инвалидларыннан, көндезге уку формасы буенча белем алучы укучылар һәм студентлардан (курсантлар), 85 яшьтәге һәм аннан өлкәнрәк затлардан кала, үзара салымны 700 сум күләмендә кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен юнәлтүгә сез ризамы:

«РИЗА» «КАРШЫ»

кабул ителгән дип танырга.

3. Гражданнар җыенның нәтиҗәләрен мәгълүмат стендларында, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында www.pravo.tatarstan.ru адресы буенча урнаштырырга.
4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Пычак авыл җирлеге башлыгы Г.Ш. Нәфыйков

ОГРН 1021607752979
ИНН 1623001928